**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Починок Кучук авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 25 октябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Кызыл Октябрь авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 6 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Кызыл Октябрь авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча шәхси йортта үткәрергә: Кызыл Октябрь авылы, Яшел ур., 22.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Кызыл Октябрь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 5000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- урам юлларына вак таш җәю (проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- урам утларын карап тоту (комплектлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- тракторны карап тоту (смета һәм документлар өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, комплектлау әйберләре сатып алу, тракторчы хезмәтләре);

- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- коеларны ремонтлау, карап тоту (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- спорт инвентаре сатып алу (смета һәм документлар өчен түләү);
- видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- вак таш җәеп, юллардагы чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Починок Кучук авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Починок-Кучук авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Гыйниятов